СОВЕТ БУРБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӨРБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«20» марта 2019 г. № 113

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә һәм Балтач муниципаль районы прокуратурасының 20.02.2019 елгы №02-01-22-2019 мәгълүмати хаты, Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлегенеж Уставы нигезендә Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл жирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 декабрендәге 108 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең 2.25 пунктта «киңлек» сүзе алдыннан “гомуми файдалану " дигән сүзтезмә өстәргә»;

1.2. 2.2 Пункт. Кагыйдәләрне киләсе редакцияләрдә бәян итәргә:

«2.2. “Төзекләндерү элементлары-декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, жиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре, шул исәптән биналарның фасадлары, төзелмәләр, корылмалар, кече архитектура формалары, стандарт булмаган корылмалар, мәгълүмат щитлары һәм территорияне төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган күрсәткечләр.”

1.3. 3.1 пунктта. «Вакытлы корылмалар» дигән сүзтезмәләрдән соң, “территорияне чүп үлән һәм куак үсемлекләре, барыннан да элек, гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч тудыручы үсемлекләр (шул исәптән Сосновский борщевигы)” сүзтезмәсе белән тулыландырырга»

2. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлауларны Бөрбаш авылы, Ф,Шакиров урамы, 18 йорт (мәдәният йорты бинасы) 15 апрель 2019 елда 10.00 сәгаттә уздырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге башлыгы Галимуллин Р.Р.га йөкләргә

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Бөрбаш авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Галимуллин

*Бөрбаш авыл җирлеге Советы*
*20.03.2019 елгы №113 карарына*
*кушымта № 1*

**Тәртип**
**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында «карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу»**

1. "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проектына тәкъдимнәр Бөрбаш авылы Ф.Шакиров урамы, 18 йорты, Бөрбаш авыл җирлеге башлыгы ярдәмчесе бүлмәсе, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр язма рәвештә кертелә.
2. Халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Бөрбаш авылы, Ф,Шакиров урамы, 18 йорт, Бөрбаш авыл җирлеге башлыгы ярдәмчесе бүлмәсе (конвертта «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты" буенча фикер алышу тамгасы белән.)

   Гаризалар эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, ачык тыңлаулар үткәрүгә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.